БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 08 2022 ел № 230

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең эш сәфәрләренә (командировкаларына) бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 елның 7 маендагы 183 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясы нигезендә, бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалану, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә җирле бюджеттан финанслана торган командировка чыгымнарына бәйле чыгымнарны түләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең эш сәфәрләренә (командировкаларына) бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 елның 7 маендагы 183 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең эш сәфәрләренә (командировкаларына) бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмәнең 4 пунктындагы б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) тәүлеклек акчаны түләүгә чыгымнар - Татарстан Республикасы территориясендә эш сәфәрендә булган һәр көн өчен 400 сум күләмендә, Татарстан Республикасыннан читтә – 400 сум күләмендә, федераль әһәмияттәге Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Севастополь шәһәрләренә эш сәфәренә җибәрелгәндә 700 сум күләмендә түләнә, «Физик культура-сәламәтләндерү, спорт һәм күнекмә (тренировка) чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 2018 елның 24 октябрендәге 324 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән каралган очраклардан тыш.»;

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына кертелгән үзгәрешләр нигезендә чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлегенә әлеге карарны муниципаль учреждение җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә үз хезмәткәрләрен кертелгән үзгәрешләр белән таныштырырга.

5. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең эш сәфәре (командировка) чыгымнарын каплаганда әлеге үзгәрешләргә таянып эш итәргә кирәк.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов